*Син – миңа, мин – синңа.*

А. Алишның нинди патша турында әкияте бар?
Исемен һәм кушаматын әйтегез.

Капкорсак-Бушборчак.

Бикбатыр һәм Биккуркак кемнәр алар?

Песи, куян

Сертотмас үрдәк әкиятендә ничә хайван катнаша?

6

Татар халык мәкале астында нинди әкияте бар?

“Аерылганны аю ашар”

“Ялкаулык-хурлык, тырышлык-зурлык”

“Мактану һәркемне хур итә, тыйнак булуга ни җитә” сүзләре кайсы әкияттән?

“Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык”

Нечкәбил чәчәктән-чәчәккә күчеп бал эчкәндә 4 бөҗәк белән очраша: озынборын,кигәвен, саранча, энә карагы. Шул бөҗәкләрне очрату тәртибендә күрсәтегез

1 Саранча

2 Озынборын

3 Кигәвен

4 Энә карагы

“ Койрыклар” әкиятендә хайваннар һәм җәнлекләр үзләренә койрык сайлап калырга ашыгалар. Мин 11 исем атыйм: куян, аю, бүре, төлке, ат, сыер, маймыл, фил, дуңгыз, эт, мәче. Әкияттә шуларның кайсысы юк?

Маймыл

Очы-кырые күренмәгән күл уртасында аккошларһәм казлар яшәгән. Аларның балалары, әниләренә килеп ... Алып кайтырга сораганнар. Әниләре аларга нәрсә алып биргән?

Велосипед

Әби күршегә Чукмарны керткәнме, әллә Тукмарнымы?

Тукмарны

# Алишның кайсы әкиятләрендә куян катнаша?

1.“Койрыклар”,

2.“Ил гизүчеләр белән хәйлә сөючеләр”,

3. “Сертотмас үрдәк”

4. “Куян кызы”

5 “Бикбатыр белән Биккуркак”

Алишнең бер хикәясендә Январь исеме телгә алына. Январь нәрсә ул?

Ала карга исеме.

Атлар арасыннан көтүче урынына сайлап куелган иң җитез, иң йөгерек атның исеме ничек?

Җирән Кашка